КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 ноябрь г.Казань № б-2658

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 27 гыйнвар, б-138 нче боерыгы белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында интернет сәүдәне үстерү программасына (чаралары планына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Электрон сәүдә мәйданчыклары аша продукция сатучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен продукция кабул итү һәм бирү пунктлары географиясен киңәйтү, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре милкендәге мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затларның хокуклары (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга электрон сәүдә мәйданчыклары аша сатыла торган продукцияне кабул итү һәм бирү пунктларын урнаштыруга бирү өчен билгеләнгән дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне арендага бирү | Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Кластерлы үсеш һәм проект идарәсе үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча), «Электрон сәүдәне үстерүгә ярдәм күрсәтү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы (килешү буенча) | даими нигездә»; |

4, 5, 13 пунктларда «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин